# КАРАР

03 декабрь 2019 ел                                                    № 1

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Кукмара муниципаль районының  Байлянгар  авылы җирлегендә Нормабаш авылы гражданнар җыены нәтиҗәләре турында.

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 01.12.2019  елда түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән, гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «Кукмара муниципаль районының Нормабаш авылы, Байлангар авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1нче  төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә кадәр өч һәм аннан күбрәк баласы  булганнар, 80 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә 1000 сум күләмендә риза булырсызмы?

- Нормабаш  авылы зират киртәсенә материаллар алу һәм зират киртәсе тоту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Нормабаш авылындагы юлларны  кыш көннәрендә кардан  чистартып тору ;
- Нормабаш авылында артезиан башнясына насослар алу;
- Нормабаш авылын яктырту өчен  лампалар сатып алу?

«РИЗА»                                                    «КАРШЫ»

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукынаия булган , җыенда катнашучылар исемлегенә, 91 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнарның саны 60
Тавыш бирүнә тиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен  60 гражданнар җыенында  катнашучытавыш бирде;  "Юк" позициясе өчен гражданнар җыенында 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян  ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Байлангар авыл җирлегендә гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.
2. Сорау буенча карарны таныргa: «2020 елда үзара салым кертүгә Кукмара муниципаль районының  Нормабаш  авылы , Байлангар авылы җирлегендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1нче төркем инвалидлардан, укучыдан һәм студентлардан (курсантлардан), 18 яшькә кадәр өч һәм аннан күбрәк баласы булганнар  ,80 яшь һәм аннан өлкәнрәк гражданнардан тыш, 2020 елда үзара салым кертүгә 1000 сум күләмендә үзара салым кертүгә килешеп торасызмы:

- Нормабаш  авылы зират киртәсенә материаллар алу һәм зират киртәсе тоту, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру;
- Нормабаш авылындагы юлларны  кыш көннәрендә кардан  чистартып тору ;

- Нормабаш авылында артезиан башнясына насослар алу;
- Нормабаш авылын яктырту өчен лампалар алу?

«РИЗА» «КАРШЫ»

-кабул ителде.

3.“Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының рәсми сайтын урнаштыру юлы белән гражданнар җыенының нәтиҗәсен бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырырга: www.pravo.tatarstan.ru,.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Авыл җирелеге башлыгы И.Х.Минегалиев